Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**30.10.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 30 октябрендә 10 сәгать 00 минутта һәм 11 сәгать 00 минутта "Әгерҗе муниципаль районының « Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1. Үләт базын киртәләү.

2.Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр челтәрләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау

2.1. Фонарьлар, лампалар, урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алыштыру; хезмәт килешүе буенча электрикка хезмәт хакы түләү һәм башка чаралар.

3. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3.1. Сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау, торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

4. Торак пуктны төзекләндерү:

4.1 Трактор тоту һәм хезмәт күрсәтү, дизель ягулыгы, дизель мае, запас частьләр сатып алырга; чүп үләннәрен чабарга, урамнарны кардан чистартырга,

хезмәт килешүе буенча трактористка хезмәт хакы түләү; роторлы чапкыч сатып алу, төзекләндерү буенча башка чыгымнар.

4.2 Паркны төзекләндерү, волейбол мәйданчыгы урнаштыруга башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?" дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 546 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 297 кеше, бу 54,4% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 297 катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы « Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны), Ітөркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 700 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1. Үләт базын киртәләү.

2.Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр челтәрләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау

2.1. Фонарьлар, лампалар, урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алыштыру; хезмәт килешүе буенча электрикка хезмәт хакы түләү һәм башка чаралар.

AnyScanner

3. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3.1. Сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау, торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

4, Торак пуктны төзекләндерү:

4.1 Трактор тоту һәм хезмәт күрсәтү, дизель ягулыгы, дизель мае, запас частьләр сатып алырга; чүп үләннәрен чабарга, урамнарны кардан чистартырга, хезмәт килешүе буенча трактористка хезмәт хакы түләү; роторлы чапкыч сатып алу, төзекләндерү буенча башка чыгымнар.

4.2 Паркны төзекләндерү, волейбол мәйданчыгы урнаштыру.

4.Карарны Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) , «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәдиев Р.Р.